ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДЂҮЛЂТ ТЉЗЕЛЕШЕН
КҮЗЂТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

---

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

24.08.2016 | г. Казань | № 59

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә
аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле
булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре
үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм
балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары,
милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында
белешмәләр тапшырырга тиеш булган
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте
вазифалары исемлеген раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 сентябрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру буенча чаралар хакында” № ПУ-636 Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” № ПУ-701 Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында” № ПУ-702 Указы нигезендә

**Б О Е Р Ы К   Б И Р Ә М:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба – Инспекция) аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлеккә (Н.А.Габсәләмова, А.З.Игнатьева):

исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән затларга дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганда 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләр, бурычлар һәм җаваплылык турында аңлатырга;

әлеге боерыкны Вазифалар исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Түбәндәге боерыклары көчен югалткан дип танырга:

2015 елның 11 августындагы “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” № 80 боерык;

4. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә шушы боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык                                                    В.А.Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү
инспекциясенең 2016 елның
“___”___________ №____
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең иң югары вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе вазифасы:
Инспекция башлыгы..
2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең төп вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
башлыкның беренче урынбасары;
башлык урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе.
3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәүче вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
Инспекциянең хокукый идарә башлыгы;
Инспекциянең аппарат бүлеге башлыгы;
Инспекциянең аппарат башлыгы урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы бүлеге башлыгы.
4. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәүче вазифалар төркемендәге “белгечләр” категориясе вазифалары:
әйдәүче киңәшче;
әйдәүче консультант;
консультант.
5. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркемендәге “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
әйдәүче белгеч-эксперт.
6. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәүче вазифалар төркемендәге “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазифалары:
әйдәүче белгеч.
7. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркемендәге “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазифалары:
1 разрядлы өлкән белгеч
2 разрядлы өлкән белгеч;

3 разрядлы өлкән белгеч.